ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» сентябрь 2020 ел. № 291

««2019 - 2023 елларга Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районында кече һәм урта
эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасы турында»
Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелүгә һәм аны гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә, шулай ук ТР Президенты Р.Н. Миңнехановның 2019 елның 23 декабрендәге ПР-315 номерлы "Татарстан Республикасы территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм" мәсьәләсе буенча видеоконференция режимында узган республика киңәшмәсе йомгаклары буенча йөкләмәләре исемлегенең 4.5 п. нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының ««2019 - 2023 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасы турында» 2020 елның 18 мартындагы 96 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«2019 - 2023 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасына 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Баженовага йөкләргә.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **И. И. Шәмсетдинов**